**ГЛАВА МАКАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**422602 Республика Татарстан Лаишевский район с.Ташкирмень ул.Мира д.40**
**тел: 8-(84378) -4-85-25**
**факс: 8-(84378) -4-85-25**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАКАРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
**422602 Татарстан Республикасы Лаеш районы Ташкирмән авылы Тынычлык урамы, 40 нче йорт**
**тел: 8-(84378) -4-85-25**
**факс: 8-(84378) -4-85-25**

---

**2025 елның 1 ноябре** **2 номер**

# КАРАР

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Лаеш муниципаль районының Макаровка авыл җирлегенең Макаровка торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лаеш муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1.2025 елның 13 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Ташкирмән авылы, Югары урам, 34 йорт адресы буенча Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлегенең Макаровка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

2.Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге Макаровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү буенча эшләр өчен түләүгә юллау

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Макаровка авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында рәсми кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Макаровка**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **С.М.Кашапов**